РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«16» апрель 2026 ел Олы Кайбыч ав. № 42

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Советының кайбер карарларының үз көчләрен
югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указының 4 пунктын үтәү йөзеннән һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 17 мартындагы 45 номерлы;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 28 гыйнварындагы 152 номерлы;

««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2014 елның 18 октябрендәге 242 номерлы;

««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр,

чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру өчен белешмәләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 31 июлендәге 86 номерлы;

«Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү хакында һәм керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 21 июлендәге 53 номерлы;

««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2014 елның 18 октябрендәге 242 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 маендагы 114 номерлы;

«Кайбыч муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 11 июлендәге 130 номерлы;

««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 17 мартындагы 45 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 30 сентябрендәге  146 номерлы»;

««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2014 елның 18 октябрендәге 242 номерлы» карарына үзгәрешләр кертү турында 2022 елның 30 сентябрендәге 147 номерлы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 18 октябрендәге 242 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 16 июлендәге 276 номерлы.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы,<br>
Совет рәисе А.И.Рәхмәтуллин